
# Тукучылык

Халкыбызның тормыш-көнкүрешендә нинди генә һөнәрләр чәчәк атмаган: данлы зәркән сәнгате, күн мозаикасы, чүлмәкчелек, тукучылык... Әнә ул, татар хатын-кызлары тукыган ашъяулыклар, паласлар, сөлгеләр. Нинди зур осталык, зәвык белән эшләнгән алар! Халкыбызның гүзәл үрнәкләре, милли орнаментлар белән тукылган кызыл башлы сөлгеләр... Борынгы әбиләребезнең күнел җәүһәрләре...

Татар хатын-кызы бөтен буш вакытын тукучылыкка багышлаган. Киндер сугып, гаиләсен киендергән, ашъяулык, палас, сөлгеләр белән өен бизәгән. Халык иҗатының матур үрнәкләре белән баетып, осталыкларын, эш коралларын бу-ыннан-буынга тапшыра килгәннәр. Ашъяулыклар, паласлар, сөлгеләр гаиләнең горурлыгы булып саналган. Аларны кадерләп саклаганнар, мирас итеп калдырганнар. Татар халкында күптөрле станнар булган. Иң киң таралганы—«Татар станы».





Тукучылык эшендә иң топ чимал—киндер һәм җитен үсемлекләре. Бик борынгы заманнарда кычыткан сүсе кулланганнар. Әйбәт уңыш алу өчен, туфракның уңдырышлы булуы кирәк. Аксакаллар киңәше белән, киндерне яшелчәлеккә, басу кырыйларына чәчкәннәр. Ә җитен уйсулыкларны, су буйларын ярата.

Уңыш җыю икс этаптан тора: иң элек басасын (киндернең орлык бирми торган өлеше-ир чәчкәсе) йолкыганнар. Киндер басасының сүсе кием-салым, көнкүреш кирәк-яраклары өчен тотылган. Орлыгы өлгергәч, киндернең әнкә чәчәклесен өзгәннәр. Ә орлыкларыннан бик тәмле май ясаганнар.


Уңыш җыйганнан соң, эшкәртү эшләре башлана. Җитенне җиргә җәеп таратканнар, һәм ул шунда өч-дүрт атна чык, яңгыр, кояш йогынтысында сүсләнеп яткан. Киндерне (берничә көлтәне бергә бастырыклап) суга салганнар. Бер ай чамасы суда сүсләнгәч, мунчада яисә ачык һавада киптергәннәр. Өлгергәнме, юкмы икәнен белү өчен, бер-ике сабак алып, талкыдан үткәргәннәр. Сүс талкыштан (киндернең кабыгы, ягъни саламы) аерылса, үсемлекләрне талкыганнар. Талкыга бәрә-бәрә талкый торгач, талкыш, сүстән аерылып, аска коела. Талкыганнан соң, сүсне агач калак (кылыч) белән шомартканнар, чистартканнар. Алай да бетмәсә, килегә салып төйгәннәр. Төя-төя, сүс чистара, йомшый, «ефәккә әйләнә». Ә аннары кабага куеп, тәрәш тарагы белән тараганнар, сүсне эрләргә әзерләгәннәр.

Җепне орчыкка эрләгәннәр. Орчык тулгач, әвернә ярдәмендә киләпкә чорнаганнар. Соңыннан җепләрне кирәкле төскә манганнар. Буяуны үзләре ясаган. Әйтик, сары төс кирәк икән, сыер теле, ат кузгалагы, зирек каерысын кулланганнар. Аларны җыеп киптергәннәр дә киледә төйгәннәр. Аннары кушылманы җылы суда эреткәннәр. Шушы эремәгә җепне салып, ике-өч сәгать кайнатканнар. Имән каерысы — кара, каен яфрагы—яшел, шомырт каерысы—куе кызыл, тал каерысы—ал төс биргән.

Киләптәге җепне әвернәгә, ә аннары тубырчага чорнаганнар. Менә шуннан соң киләп сару (буй җебе озату) эшенә керешәсең. Җепне стенада яисә махсус озаткычта озатканнар. Киләп сарганда, зур игътибар сорала: тукыган вакытта аскы һәм өске рәтләргә аерылсын өчен, алар арасына аркылы җеп куеп калдырырга кирәк. Җепне озатканнан соң, туку станын корганнар. Буй җепне башта көре күзләренә кигертәсең, аннары кылыч аша үткәреп, таякка бәйләп куясың. Ә көреләрне тәбәлдереккә бәйлиләр. Тәбәлдереккә басу белән, көреләр хәрәкәткә килә, эш башлана. Кулдагы соса әле бер, әле икенче якка йөгерә, буй һәм аркылы җепләр бергә үрелеп, тукыма барлыкка килә.



ТАЛКЫ



ӘВЕРНӘ ТӨБЕ




ОРЧЫК




ТӘРӘШ ТАРАГЫ



ТӘРӘШЛЕ КАБА



ТУБЫРЧА




КЫЛЫЧ



СОСА. ЭЧЕНДӘ ШҮРЕ



КӨРЕ



ҖЕПНЕ СТЕНАДА ОЗАТКАННАР



ТӘБӘЛДЕРЕК

# Милли ашлар

Халкыбыз элек-электән аш-суга оста булган, камыр ризыклары да пешергән. Көндәлек ризык төрләрендә сөт (май, катык, эремчек) һәм ит ризыклары, ярмадан боткалар, киселгән токмачлы аш өстенлек иткән. Бәйрәмнәрдә, өмә вакытларында камыр ризыклары пешергәннәр. Иң яратып пешерелә һәм ашала торган ризыклардан бәлеш, коймак, гөбәдия, чәк-чәк, кош теле (чәй токмачы), өчпочмак, кыстыбый (күзикмәк), пирәмәч саналган.



Кош теле (чәй токмачы)



Чәк-чәк



Гөбәдия



Кабак бәлеше



Өчпочмак



Бәлеш



Мич коймагы



Кыстыбый

# Өй-торак



Бабаларыбыз элек-электән авылда тормыш алып барган, һәм биредә алар тораклар, йортлар төзегән. Урамнар тыкрыклар белән кисешкән. Гадәттә, мәчет, кибетләр, җәмәгать амбарлары, кайчакта мәктәпләр, янгын сүндерү сарайлары үзәктә урнашкан. Аның тирә-юне көтүлекләр өчен файдаланылган, басу капкасы, киртә белән әйләндереп алынган. Утарлар 2 өлешкә - ишегалды һәм ындыр якка бүленеп, ишегалдында - йорт, келәт, амбар, терлек өчен каралты-кура, еш кына җәйге аш алачыгы; ындыр ягында бәрәңге бакчасы, мунча, кибәнлек, әвен урнашкан. Утар җирләре җитмәгәндә, бәрәңге бакчасы һәм ындыр еш кына авыл читендә урнашкан: гаилә үскән һәм утар җирендә, башка чыгару гадәте буенча, өйләнгән улларга йортлар салынган. Ишегаллары ачык һавалы урында корылган. Урам якка капка урнаштырылган, тоташ бүрәнәләрдән, тактадан, кайчакта таштан салынган биек койма белән әйләндерелгән. Капкага һәм коймаларга бизәкләр төшерелә, алар төрле төсләргә буяла. Аның каршындагы тоташ койманың бер өлешен беркадәр тәбәнәгәйтеп, аңа челтәрле рәшәткә өстәлә. Өй түренә шомырт, миләш агачлары, чәчәкләр утыртып бакча ясала. Безнең татар өйләре, тәрәзә кырыйлары, өй стенасы чит-читләре, кыеклары милли бизәкләргә бай булган.



Татар өенең күп урынын мич алып торган. Ул-өйне җылытучы да, ямь биреп торучы да. Мич янында ризык пешергәндә кулланыла торган җиһазлар торган: табагач, кисәү агачы, чүлмәкләр. Өй эчендә тагын сәке, өстәл, урындык, эскәмия торган. Такта сәке-шулай ук күптөрле вазифаны үтәүче җиһаз. Анда йоклаганнар да, утырганнар да, эскәмия роленә дә кергән. Ул чаршау белән бүленеп алынган булырга да мөмкин. Өстәл зур, барлык өй кешеләрен дә сыйдыра алырлык булган. Өстәл түрендә зур самовар утырган. Ул күмер белән кайнатылган, аның торбасы өчен мичтә аерым төннек-морҗа юлы калдырылган.

# Киемнәребез

Өс кием эчке һәм тышкы, язгы-көзге, җәйге-кышкы кием төрләрен үз эченә ала. Киемдәге төсләр аерымлыгы хуҗасының яшенә бәйле. Мәсәлән, кара казакига күнеккән ир-ат, олыгая төшкәч, казакины ак тукымадан да тектерә. Ак төс, башка төрки халыклардагы кебек, сафлык һәм картлык билгесе: кызларда ак калфаклар, ак бәрән туннар булса, өлкәнрәк яшьтәге хатыннарда ак тастар, ак яулык һ.б. киемнәр булган. Кызыл төс—яшьләргә хас.

Кием комплексының нигезен күлмәк белән ыштан (соңрак — чалбар) тәшкил итә.

**Ирләр күлмәге** мамык, җитен, киндер җебеннән тукылган материядән озын, тоташ буйлы, киң чабулы итеп тегелгән. Изүе күкрәк уртасына туры килеп, муен уемына утыртма яисә кайтарма яка куелган, муен янына изү бавы сыярлык элмәкләр беркетелгән яки тишек ясалган. Күлмәк иркен һәм озын булып, ыштан (чалбар) өстенә төшеп торган.

**Хатын-кыз күлмәге.** Хатын-кызларның күлмәге тоташ яки өзек буйлы, такма итәкле итеп тегелгән һәм изү кырыйларын, җиң һәм итәк очларын чиккәннәр. Күлмәкнең күкрәк өлешенә укадан эшләнгән алынмалы изү беркеткәннәр. Купшы бала итәкләр кую күлмәкне тагын да киңрәк һәм җиңелрәк итеп күрсәтә. Хатын-кызларның киеменә хас нәрсә — күкрәкчә. Аны күлмәк астыннан муеннарына бәйләп калдырганнар.

**Ыштан.** Аның да гадәттәге өлгесе ирләр һәм хатыннар өчен бер булып, безнең халыкның борынгы тормыш-көнкүрешенә (идәнгә, сәкегә аяк бөкләп утыру һ.б.) җайлашкан форманы тәшкил итә. XIX йөз ахырында ук ирләрдә кара төстәге фабрика тукымасыннан **чалбар**лар урын ала.




**Алъяпкыч**. Аны ирләр дә, хатыннар да үз иткән, ул эш киеме генә түгел, ә көндәлек кием булып та саналган.

**Камзул**. Ирләр аны өйдә кигәннәр. Ул чабулы, ябык күкрәкле, тар утыртма якалы, өч яки биш билле һәм тезгә җитәр-җитмәс озынлыкта булган. К**азаки** — озын җиңле һәм озын буйлы, өч билле, ябык күкрәкле язгы һәм җәйге өс киеме. Биш билле озын өс киеменә **бишмәт** диләр. Бишмәт мамык белән сырылса, аңа **сырма** да диләр.

**Тун белән толып** иләнгән тиредән тукыма белән тышлап эшләнгән.

Авылда электән кулы эш белә торган осталар-тәрәзә куючы, мич чыгаручы, итеккә олтан салучы, чабата үрүче, умартачылар булган.

Элек мич чыгару өчен кирпечен дә үзләре сукканнар. Мәмәширдә дә мич салу осталары-, Вәлиуллин Галимулла, Сәмигуллин Минемулла, Хәйруллин Шәрифулла, Галимуллин Галиәхмәт, Кадыров Вәли, Хәлиуллин Минегали, Тәмәйдә-Габдрәшитов Мәҗит, ә Хаҗиев Фазлый абыйның әтисе Хаҗиәхмәт ага, Гәрәев Вәккас, Гайфуллин Гыйззәтулла үзләре кирпеч сугучы булган.


Гәрәев Вәккас


Хәйруллин Шәрифулла

Умарта тоту да бик мәшәкатьле эшләрдән санала. Авылда электән бал кортларын асраучылардан Газизуллин Шәрип, Габидуллин Низаметдин, Әсхәдуллина Тофак апа (колхоз умарталыгында да эшләгән), Нигмәтуллин Хәкимулла, Тәмәйдә Шәфигуллин Мөхлисулланы күрсәтергә булыр иде.


Әсхәдуллина Тофак


Газизуллин Шәрип


Мусина Нурания

Чабата үрү-иң кирәкле һөнәр булган. Чабатаны оста итеп үрүчеләр: Нигмәтулли-на Шәрәфи, Абдуллина Минекамал, Габдрахманова Хәдичә, Әхәтов Минехәмәт, Сабирова Бәдри, Вәлиуллина Камилә, Сәмигуллина Гатифә, Гыйльманов Вәлиулла, Шәфигуллин Мотигулла, ә Тәмәйдән-Мәннәнова Әлфия, Мусина Нурания апалар булган.


Фатыйхов Нигмәтулла

Авылда үзе такта яргыч ясап, көн күргән кешеләр дә булган. Шуларның берсе-Фатыйхов Нигмәтулла. Шул ук вакытта оста итекче дә булган.